Закирова Л.Н., Денмөхәммәтова Э.Н

# А.С. ПУШКИННЫҢ “СКАЗКА О РЫБАКЕ И РЫБКЕ” ӘКИЯТЕН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Бөек әдипләрнең күренекле әсәрләрен бер телдән икенчесенә тәрҗемә итү кызыклы һәм кирәкле гамәл исәпләнә. Шунлыктан классик әсәрләрнең берничә телгә тәрҗемәләре бар, ә кайберләренең бер үк телдә дә берничә тәрҗемәсе булырга мөмкин. Күренекле рус шагыйре А.С. Пушкин әсәрләре дә күп телләргә, берничә тапкыр тәрҗемә ителгәннәрдән исәпләнә, шул исәптән татар теленә дә.

А.С.Пушкин әсәрләрен беренче мәртәбә татар теленә тәрҗемә итү эшчәнлеге XIX гасырның 90 нчы елларында башлана һәм бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Әдипнең күпсанлы шигырьләре белән беррәттән “Евгений Онегин”, “Дубровский”, “Руслан һәм Людмила” кебек зур күләмле әсәрләре төрле буын тәрҗемәчеләр – Г.Рахманкулый, М.Өметбаев, Г.Тукай, А.Шамов, Ф.Бурнаш, Зөлфәт һ.б. тарафыннан тәрҗемә ителгән. Гомумән алганда, татар телендә А.С.Пушкинның сайланма әсәрләре 6 тапкыр, шигырь, әкият, романнары, аерым китап булып, 47 тапкыр басылып чыккан һәм барлыгы 408 000 тиражны тәшкил итә (1, 58).

А.С.Пушкинның балалар өчен язылган әсәрләреннән иң күп тәрҗемә ителгәне – “Сказка о рыбаке и рыбке” әкияте (1833). Бу әсәрнең дүрт тәрҗемәсе билгеле: Г.Рахманкулый тарафыннан тәрҗемә ителгән “Балыкчы һәм балык” (1901), И.Байчераковның “Алтын балык” (1919), Ф.Кәримнең “Алтын балык белән балыкчы карт турында әкият” (1946), Ә.Исхак тәрҗемә иткән “Балыкчы һәм балык турында әкият” (1949) вариантлары. Тәрҗемә текстларның лексик-семантик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләрен тикшерү нигезендә түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкин:.

1. Рус теленнән татар теленә **лексик сурәтләү чараларын** тәрҗемә иткәндә берничә төрле ысул кулланылган:

а) метафора, чагыштыру кебек троплар, фразеологизмнар, синоним һәм контекстуаль антонимнар сүзгә-сүз тәрҗемә ителгәннәр: *черная буря – кап-*

*кара давыл (Ә.И., Ф.К.); неспокойно синее море – диңгез бер дә тын түгел (Ф.К.); не садися не в свои сани – утырма кеше чанасына (Ә.И.), чит чана икән, аңа утырма (Ф.К.); пошел, отправился, идет – тотты юл, юнәлде, бара (И.Б.); разбитое корыто - новое корыто – ярык тагарак - яңа тагарак (Ә.И., Г.Р.).*

ә) кайбер метафора һәм антонимнарның бер компонентын үзгәртеп тәрҗемә итү күзәтелә: *заморские вины – кыйммәтле эчемлек (Ә.И.); высокий терем - царские палаты – биек сарай - патша сарае (Ф.К.).*

б) фразеологизмнарны тәрҗемә итүдә компенсация ысулы файдаланылган. Мәсәлән, *на чем свет стоит ругает* тотрыклы гыйбарәсе барлык тәрҗемәчеләр тарафыннан гадиләштерелеп бирелгән: *бик каты тиргәгән картны (Ә.И.); карчык тагын да катырак тирги (Ф.К.); картын орыша, ачуы тагын да кабарган төялеп (И.Б.); әрли башлый тагын да (Г.Р.).* Ләкин рус телендәге фразеологизмның төп мәгънәсе сакланып калган дип исәплибез.

в) архаизмнар татар телендә гомуми кулланылышта йөри торган сүзләр белән тәрҗемә ителгәннәр: *перстни – балдак (Г.Р.), йөзек (Ф.К., И.Б., Ә.И.); очи – күз (Г.Р., Ф.К., Ә.И., И.Б.);*

г) Г.Рахманкулый һәм И.Байчераков тәрҗемәләрендә гарәп-фарсы, рус алынмаларына зур урын бирелгән: *дахи, арзу, рәгаят, ыспурлашу, рюмка, нәчәлник, землянка һ.б.* Ф.Кәрим һәм Ә.Исхак тәрҗемәләре хәзерге татар әдәби теле нормаларына якын торулары, камил рифма һәм ритмга корылган булулары белән калган тәрҗемәләрдән аерылып тора.

2. Тәрҗемәләрне **морфологик яктан** тикшергәндә, исемдә килеш категориясен тәрҗемә итү үзенчәлекле булуы ачыкланды. Рус һәм татар телләрендә килешләр үзләренең мәгънәләре белән бер-берсеннән аерыла, шуңа күрә тәрҗемә вакытында рус телендәге падежны татар телендә берничә килеш кушымчасы, бәйлек һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә бирә алу мөмкинлеге барлыкка килгән. Мәсәлән, *дательный падежда* килгән исем татар теленә *юнәлеш килеше кушымчасы, юнәлеш килеше кушымчасы* +

*табан бәйлек сүзе, баш килеш + таба, буена бәйлек сүзләре* төзелмәләре белән тәрҗемә ителгән: *пошел к морю – диңгезгә бара (Г.Р.), диңгезгә табан барган (Ф.К.), диңгез буена барган (Ә.И.).* Безнең карашыбызча, бу очракта тәрҗемәнең соңгы варианты уңышлырак.

Рус телендәге үткән заман хикәя фигыльнең татар телендә бирелеше кызыклы. И.Байчераковта ул категорик үткән заман хикәя фигыль формасы; Ә.Исхак, Ф.Кәрим, Г.Рахманкулый тәрҗемәләрендә нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль формасы белән бирелгән. Кайбер очракларда бу форманың хәзерге заман хикәя фигыль булып тәрҗемә ителүе дә күзәтелде. Мәсәлән: *воротился – кайтты (И.Б.), кайткан (Ә.И.), кайта (Ф.К., Г.Р.).* Әсәрнең экият жанрында язылу үзенчәлеген исәпкә алганда, нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль формасын куллану дөрес булыр дип уйлыйбыз.

Рус телендәге фигыльгә хас вид категориясе мәгънәләрен бирү өчен тәрҗемәләрдә ярдәмче фигыльләр уңышлы файдаланылган. Совершенный вид мәгънәсен бирүдә *китү, алу, җибәрү, җитү, бетү, керешү* кебек ярдәмче фигыльләр белән килгән конструкцияләр кулланылган: *ушла – йөзеп китте (И.Б.); поймал – тотып алдым (Г.Р.).* Несовершенный вид мәгънәсе *яту, тору* ярдәмче фигыльләре ярдәмендә бирелгән: *пряла – эрләп яткан (Ф.К.) һ.б.*

3. Тәрҗемәләрнең **синтаксик** үзенчәлеге булып хикәя җөмләдә тема-реманың бирелеше санала. Кагыйдә буларак, рус телендә яңалык (рема) һәрвакыт җөмләнең ахырында урнаша, татар телендә исә хәбәр алдыннан килгән сүз рема була. Бу үзенчәлекне исәпкә алмаганда, мәгънә үзгәрә. Мәсәлән, *Воротился старик ко старухе* җөмләсендә логик басым *ко старухе* сүзенә төшә. И.Байчераков бу үзгәрешне дөрес тотып алган һәм *Кайтты карт карчык янына* дип тәрҗемә иткән. Ф.Кәрим тәрҗемәсендә картның *җир өенә* кайтуы әһәмиятле булып яңгырый, ягъни оригиналдагы мәгънә үзгәрә: *Карт җир өенә кайта яңадан.* Ә.Исхак тәрҗемәсендә – *Карт тагын кайткан карчык янына* – логик басым *тагын* сүзенә төшә, шулай итеп, татар укучысына информация дөрес җиткерелми.

Лингвистик тикшеренүләр күрсәткәнчә, тәрҗемәләрдә татар теленең күп кенә грамматик формалары чагылыш тапкан. Бу тагын бер тапкыр татар теленең гаять бай лексик һәм грамматик мөмкинлекләргә ия тел булуын дәлилли. Гомумән, барлык тәрҗемәчеләр дә оригинал текстның төп мәгънәсен, эчтәлеген, укучыга эстетик тәэсир итү дәрәҗәсен мөмкин кадәр тулы, төгәл саклап калырга тырышканнар дип әйтеп була.

**Әдәбият исемлеге**

1. Байрамова Л.К. Татарстан: Языковая симметрия и ассиметрия / Л.К.Байрамова . – Казань: КГУ, 2001. – 267с.